ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«26» октября 2022 г. № 959

**2022 елның IV кварталына Арча муниципаль районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында**

Арча муниципаль районында «Татарстан Республикасы бәяләүчеләре берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгы тарафыннан торак урыннарның 1 квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча («Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2022 елның 27 нче гыйнварындагы 17 номнрлы хаты) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 8888 номерлы карары белән расланган «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Барлык категория гражданнар өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урыннар сатып алуга (төзүгә) бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәплəп чыгару өчен Арча муниципаль районы буенча 2022 елның IV кварталына торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен 49018 (кырык тугыз мең унсигез) сум күләмендә расларга.

2.«2022 елга Арча муниципаль районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 27 маендагы 398 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609009516

Җитәкче Р.М.Гатиятов